*Шакурова М. М. (КФУ, Казань)*

# ТЕЛ ҺӘМ СӨЙЛӘМ МАТЕРИАЛЫ БУЛАРАК ТЕКСТ

**Аннотация:** Использование языкового и речевого материала в иноязычной аудитории приводит к желаемому результату, так как доработанный текст является основой для реализации всех видов речевой деятельности (аудирование, говорение, чтение и письмо). Лингвострановедение позволяет комплексно решать важнейшие задачи обучения языку, а это дает нам право рассматривать весь материал как одно из возможных средств углубления взаимосвязанных разделов языкознания. Между текстами и грамматическим строем языка существуют внутренние связи. Один как бы является рычагом для другого. Таким рычагом для грамматического строя является текст в лингвострановедческом аспекте. С конца XVIII – до конца XX в. азбуки, учебники, грамматики, самоучители, разговорники И.Хальфина, И.Гиганова, А.Троянского, К.Насыри, Г.Ибрагимова, М.Курбангалиева, Р.С.Газизова, В.Н.Хангильдина, Ф.Ю.Юсупов, Р.А.Юсупов, И.Л.Литвинов и др. оказали большое влияние на дальнейшее развитие методики преподавания татарского языка в иноязычной аудитории. В них даются тексты и диалоги, на примере которых подробно рассматриваются.

**Ключевые слова:** методика преподавания татарского языка, методисты XX века, лингвострановедение, речевой материал, языковой материал, школьный учебник.

**The text is a speech and language material**

**Summary:** The use of language and speech material in a foreign language audience leads to the desired result, as the revised text is the basis for the realization of all kinds of speech activities (listening, speaking, reading and writing). Lingvostranovedeniya allows to solve the most important problem of language learning, and it gives us the right to review all of the material as one of the possible means of deepening inter-related sections of linguistics. Between the text and the grammatical structure of the language, there are internal connections. One is as though the lever for another. That lever is the grammatical structure of the text in the lingvostranovedcheskogo aspect. Since the end of XVIII - until the end of the twentieth century. ABC, textbooks, grammar tutorials, conversation I.Halfina, I.Giganova, A.Troyanskogo, K.Nasyri, G.Ibragimova, M.Kurbangalieva, R.S.Gazizova, V.N.Hangildina, F.Yu.Yusupov , R.A.Yusupov, I.L.Litvinov et al. had a great influence on the further development of methods of teaching the Tatar language in a foreign audience. They are texts and dialogues, the example of which the details are considered.

**Key words:** methodology of teaching the Tatar language, methodist XX century, lingvostranovedeniya, speech material, language material, school books.

Җәмгыятьтә үзгәртеп кору җилләре татар телен укыту методикасының 200 елдан артык зур тарихын да читләтеп үтмәде. Соңгы елларда XVII гасыр ахыры XX гасыр башларында телгә өйрәтү методикасына үзләреннән өлеш керткән бер төркем методистларны барлау, аларның хезмәтләрен өйрәнү кирәклеге ачыкланды: XX гасыр башларыннан бүгенге көнгә кадәрге чорда татар телен укыту методикасында үзләреннән тирән эз калдырган методистлар, аларның төп хезмәтләре барланды, методик эшчәнлекләре ачыкланды: К.Насыйри, Г.Ибраһимов, Г.Сәгъди, М.Х.Корбангалиев, Р.С.Газизов, Ш.Рамазанов, В.Н.Хангилдин, М.З.Зәкиев, Ф.А.Ганиев, Д.Г.Тумашева, З.М.Вәлиуллина, Ф.С.Сафиуллина, К.З.Зиннәтуллина, С.М.Ибрагимов, Ф.М.Хисамова, Л.З.Шакирова, Ф.Ф.Харисов, И.Л.Литвинов, Р.З.Хәйдәрова һ.б.

Татар телен гамәлгә кую барышында аны укытуның эчтәлеген, максат, бурычла-

рын төгәлләштерү, ысул һәм алымнарын төрлеләндерү, камилләштерү, яңа буын дәреслекләр һәм программалар төзү алгы планга куелды. Татар теленнән белем бирүнең сыйфатын арттыру теоретик материалны аңлату барышында, белем бирү белән беррәттән, укучыларда телгә карата кызыксыну уятуны һәм дөрес итеп сөйләшергә, укырга һәм язарга, фикерләргә өйрәтүне таләп итә. Татар телен укытуның сыйфатын күтәрү, башлангыч сыйныфтан алып туган телне эзлекле үзләштерү, сөйләмне дөрес төзеп, әдәби тел нормаларына туры китереп, телдән һәм язма рәвештә башкаларга җиткерә белү – бүгенге көн уку-укыту мәсьәләләреннән иң мөһиме булып тора. Дәресләрдә тел һәм сөйләм материалы аша татар халкының тормыш-көнкүреше, гореф-гадәтләре һәм йолалары, милли бәйрәмнәре һәм ризыклары турында мәгълүмат бирү, халык авыз иҗаты үрнәкләре белән таныштыру, укучыларның туган җире турында танып-белү мөмкинлекләрен арттыру (страноведение) үзәктә тора.

Мәктәп дәреслекләренә сөйләм материалын сайлау, текстлар белән эшләү мәсьәләсе XX гасырның башларында ук игътибар үзәгендә тора. М.Х.Корбангалиевнең “Татар теле дәреслеге. Башлангыч мәктәп өчен” (1938), “Татар теле дәреслеге. Грамматика һәм дөрес язу” (1945), “Татар теле грамматикасы. Синтаксис” (1962) дигән китаплары кат-кат бастырыла. Автор әлеге дәреслекләрне төзүдә текстлар сайлауга да зур игътибар бирә. “Татар теле дәреслеге” (1938) беренче сыйныфларны күз уңында тотып язылган. Әлеге дәреслек мәктәп бусагасын атлап керүче сабыйларны кечкенә генә өзекләр аша тормыш, аларны чолган алган әйләнә-тирә белән таныштыра. Дәреслектә рәсемнәр, күренекле шәхесләрнең портретлары (Ленин, Стаханов, Паша Ангелина, Максим Горький һ.б.) урын алган, логунглар (СССРда хезмәт -дан эше, намус эше, батырлык һәм геройлык эше һ.б.), плакатлар һәм таблицалар (“Бәйлек сүзләр”, “Күрсәтү алмашлыкларының килеш белән төрләнеше”, “Исемнәрнең берлек һәм күплек саны” һ.б.) урнаштырылган. [3]. Текстлар аңлап укырга-язарга өйрәтү, балаларны матур язуга күнектерү, җөмләләр төзү, аларның фикерләү сәләтләрен, сөйләм телен үстерүне күздә тотып сайлап алынган: хайваннар дөньясы, ел фасыллары, сугышта дошманны җиңү. “Сугышта дошманны җиңү” дигән циклга караган текстлар бер-берсе белән логик эзлеклелектә бирелгән: “Алмаз абый” (2 нче бирем, 15

нче бит); “Без” (3 нче бирем, 15 нче бит); “Диңгездә” (7 нче бирем, 16 нчы бит); “Кыйна дошманны” (6 нчы бирем, 18 нче бит); “Батыр бул” (7 нче бирем, 19 нчы бит); “Илеңне сакла” (8 нче бирем, 19 нчы бит); “Фашистларга үлем” (1 нче бирем, 23 нче бит). [3, с. 23]

Ике шигырьнең авторы күрсәтелгән, димәк, калган текстларны үзе уйлап чыгарган. Укучылар хайваннарны, кошларны фигыльләр белән бергә үреп өйрәнгәннәр: Эт өрә. - Эт нишли? Бүре улый. Күгәрчен гөрли. Ат кешни. Сыер мөгри. Сандагач сайрый. Тавык кытаклый [3, с. 3]

М.Х.Корбангалиевнең “Татар теле дәреслеге. Грамматика һәм дөрес язу” (1945) китабы бай мәгълүматлы: хикәя, сорау, өндәү җөмләләр, эндәш сүз, берничә ияле һәм хәбәрле, тиңдәш иярчен кисәкле җөмләләр, баш һәм иярчен җөмлә, туры сөйләм; исемнәрнең тартым белән төрләнеше, тартым кушымчалары белән төрләнгән исемнәрнең килеш белән төрләнеше, чагыштыру һәм арттыру дәрәҗәсендәге сыйфатлар, боерык фигыль, рәвеш, бәйлекләр, теркәгечләр, кушма сүзләр, кыскартылган сүзләр һ.б. Китапта өч схема үрнәк итеп тәкъдим ителә. Әлеге дәреслектә галим текстларны шулай ук өч өлешкә бүлә:

1) кызыл армия,
2) күренекле әдипләр, шәхесләр,
3) файдалы киңәшләр.

Биредә текстларның кайдан, кемнән алынуы төгәл күрсәтелгән. [4]

М.Х.Корбангалиевнең “Татар теле грамматикасы. Синтаксис” (1960) дәреслеге (Х.Хисматуллин, Р.Шакирова белән берлектә) 6-7 нче сыйныф укучыларын күздә тотып язылган: гади җөмләләр (Вокзал китүчеләр белән тулы. Без тиз генә перронга чыктык. - Кайсын әйтәсең, Газиз? Теге кулакларга 18 сәгать эшләп, ач торган вакытныммы? - Әткәй, әгәр шулай булса? һ.б.), җөмләнең баш кисәкләре, кушма җөмлә, тезмә кушма җөмлә, иярченле кушма җөмлә, туры сөйләм һ.б. Дәреслек барлыгы 158 биттән тора. Текстларның эчтәлегенә карап, түбәндәге темаларны аерып чыгарырга була:

1) мәктәп,
2) туган як,
3) күренекле галимнәр,
4) ел фасыллары,
5) хайваннар бакчасы.

Бу китап тагын шунысы белән үзенчәлекле: дәреслек ахырында автор беренче тапкыр татарча-русча терминнар сүзлеген урнаштыра. Дәреслектә хикәя, шигырь, табышмак, җыр кебек әдәби материал урнаштырылган.

Мәкалләрнең күп булуы күзгә ташлана: Ябага тайны хурлама, язга чыккач ат булыр; Яхшы белән юлдаш булсаң, эшең бетәр, Яман белән юлдаш булсаң, башың бетәр; Чебешне көз көне саныйлар һ.б. [5]. Текстлар нигездә Г.Тукай, Ф.Кәрим, М.Җәлил, Г.Гобәй, К.Нәҗми, М.Максуд, Һ.Такташ, Т.Гыйззәт һ.б. әсәрләреннән алынган. Бу өзекләргә карап, автор укучыларда әхлакый сыйфатлар булдыру, туган илне саклау, үз эшен белеп эшләүче яхшы эшчеләр тәрбияләүне күздә тота.

М.Корбангалиев грамматиканың (сарыф вә нәхү дәресләре) сөйләү һәм язу телен үстерүдәге әһәмиятен, өйрәтү ысулларын барлый. Шулардан бер ысулга аерым тукталып үтәсе килә. Тикшерү (тәхлил) ысулы методикада фәнни һәм гамәли ысуллардан санала. Методист җөмләгә яки сүз төркемнәренә анализ ясаганда, синтаксисны һәм морфологияне тирәнтен үзләштереп, гамәли куллана белү дә кирәк, ди. Мәсәлән, «Гали балык тотты», «Гали балык тоткан» дигән җөмләләрдә ия дә, хәбәр дә ачыклангач, автор «тотты» белән «тоткан» фигыльләренең бер-берсеннән аермасын таптыра: «тотты» дигәндә, Галинең балык тотканын сөйләүче күзе белән күргән буламы? «Тоткан» дигәндә, Галинең балык тотканын сөйләүче күзе белән күргән буламы? (158 нче бит). [2, с. 157]

«Укыттырмак» дигән сүзне сүз төзелеше ягыннан тикшергәндә (тамыр -укы-; -т, -тыр - мәҗбүр итү өчен булган ялгаулыклар) М.М.Корбангалиев иң элек кемне кемнән укыту мәгънәсен ачыкларга куша [2] (Тикшерү барышында балага «сүзнең мәгънәсе һәм сүзнең тышкы рәвеше алмашыну белән ул мәгънәнең үзгәрүенә (китап, китапчык, йөртмәк, йөрттермәк)» сәбәп булуын искәртә. Шулай итеп, тикшерү ысулы белән эшләгәндә, кагыйдәләр кабат искә төшерелә, ныгытыла. Укучы иҗади эшли.

1938 елда В.Н.Хангилдин (Х.Шабанов белән берлектә) “Грамматика һәм орфография дәреслеге”н чыгара. Бу дәреслектә “Белешмә өчен хәрефләр - әлифба”, “Каләмне менә болай тот”, “Баш хәрефләр язылышын күзәтегез”, “Үрнәктәгечә матур итеп языгыз” кебек күнегү-биремнәр, плакатлар урнаштырылган. Текстларда патша Россиясе, 1936-37 елларда гомуми белем мәктәпләрендә укучы балаларның саны, күләме, уку йортлары, халыкның яшәү шартлары, батыр сугышчылар, 1 нче май, ел фасыллары турында мәгълүмат бирелгән.

Мәсәлән: 1936-37 нче елда гомуми белем мәктәпләрендә 27 миллион 400 мең кеше укыды. Техникумнарда 767 мең кеше укыды. 1935-36 нчы елда югары уку йортларында 525 мең кеше укыды. Дәүләт тарафыннан 1935 нче елда 8 миллиард 300 миллион сум акча тотылды. 1924 нче елдан алып, 1935 нче елга кадәр булган вакыт эчендә 23 миллион 800 мең кеше башлангыч белем алды. СССР халыкларының культура дәрәҗәләре көннән-көн үсә бара. [6: 5]

Алга таба барлык күнегүләр диярлек теоретик материалны гамәли яктан ныгытуга корылган. Авторлар үзләре тәкъдим иткән текстлардан тыш, Г.Тукай, Һ.Такташ, Г.Ибраһимов, Ш.Камал, М.Горький, М.Әмирдән алган текстлар белән дә эшлиләр. Сөйләм материалын үстерү өчен сайланган текстларда татар авыллары, аның табигате, гүзәл кешеләре турында күп мәгълүмат табып була.

1960 елда Р.С.Газизовның “Татарский язык” дигән китабы чыга. Автор әлеге дәреслекнең максаты итеп татар тел белеменең фонетика, морфология һәм синтаксис тармаклары турында ныклы белем бирү, дөрес укырга һәм тәрҗемә итәргә, текст белән эшләргә өйрәтүне куя. Бу китап дүрт өлештән тора: 1) теоретик материал (фонетика, морфология, синтаксис), 2) русчадан татарчага тәрҗемә итү материалы урнаштырылган («Случай на границе», “Наша Родина”, “Два товарища” һ.б.), 3) татарчадан русчага тәрҗемә итү өчен күнегүләр (Г.Тукайның “Кәҗә белән сарык”, “Шүрәле”, “Мужик йокысы”, “Көз” һ.б.), 4) уку материалы бар (“Исемдә калганнар” (Г.Тукай), “Көтүчеләр” (Г.Ибраһимов), “Ялчы” (М.Гафури), “Беренче театр” (Г.Камал), “Алар өчәү иде” (И.Гази) һ.б.) [1: с. 250]. Укучылар башта теоретик материалны үзләштерәләр һәм соңыннан тәрҗемәләр, уку материаллары аша алган белемнәрне ныгыталар. Татар теленә өйрәтүдә әлеге эш төрләре иң мөһимнәреннән санала. Автор, текстлар белән бәйләп, диалогик һәм монологик сөйләм үстерү күнегүләре дә тәкъдим иткән булса, бу китапның кыйммәтен тагын да арттырган булыр иде. Ләкин Р.С.Газизов тәрҗемә итү һәм уку өчен тәкъдим иткән текстларның бурычларын түбәндәгечә билгели:

1. Уку күнекмәләрен булдыру.

2. Татар милли әдәбияты белән танышу.

3. Автобиографик әсәрләр аркылы татар язучыларының тормыш юллары белән таныштыру.

4. Укучыларның дөньяга

карашларын үстерү.

5. Предметара бәйләнешне булдыру (тарих, әдәбият, география һ.б.).

Бүгенге көн дәреслекләренең эчтәлегенә килгәндә, темаара бәйләнеш сакланган, билгеле бер эзлеклелек, системалылык бар: мәктәптә, өйдә үзүзеңне тота белү, әдәпле булу, кунакка йөри белү серләре, гаиләне ярату, йорт хайваннары турында кызыклы мәгълүматлар, Яңа ел бәйрәме һәм аны үткәрү тәртипләре, татар авыллары тарихы, бөҗәкләр, дару үләннәре, яз аеның серләре, һ.б. - барысы да сөйләмә телне үстерүгә корылган (Ф.С.Сафиуллина, К.С.Фатхуллова, И.Л.Литвинов, Р.З.Хәйдәрова, Р.Р.Нигъматуллина). Дәреслекләр бик нык уйлап эшләнелгән һәм авторлар зур хезмәт куеп, эшне яратып башкарганнар. Татар телен чит тел буларак укыту өлкәсендә аларның бай тәҗрибә туплаганлыгы әллә каян күренеп тора: дәреслекләрдә укучыларның яшь үзенчәлекләрен истә тотыла; дәреслекнең эчтәлеге кызыклы, темаара бәйләнеш сакланган; сайлаган текстлар, диалоглар һәм күнегүләр аңлаешлы, татар телендә аралашуга, сөйләшүгә теләк уята торган (әлбәттә, кайберләре күләме ягыннан аерылып тора); бик матур рәсемнәр, иллюстрацияләр телгә өйрәнү барышын җиңелләштерү максатыннан тәкъдим ителә; тестлар материалны аңлау-аңламауларын тикшереп карау өчен дә, укучыларны иҗади фикерләргә өйрәтү йөзеннән дә чыгып төзелгән һ.б. [7, с. 212]. Бүгенге көндә ФГОС буенча төзелгән яңа дәреслекләр коммуникатив, социомәдәни һәм лингвистик компетенцияләргә нигезләп языла, ягъни укучы теләсә нинди кыен ситуациядән чыга белергә, нәрсә турында сүз барганлыгын чамаларга, үзен ышанычлы тотарга, тел күренешләрен функциональ яктан, ягъни сөйләм оештырудагы роленнән чыгып кулланырга, сорауларга аңлап җавап бирергә тиеш.

Әдәбият исемлеге

1. Газизов Р. Татарский язык (для самостоятельно изучающих) / Р.Газизов. - Казань: Татгосиздат, 1960. - 250 с.

2. Корбангалиев М.Х. Ана теле методикасы / М.Х.Корбангалиев. - Казан: “Корылтай”, 1920. - 245 б.

3. Корбангалиев М.Х. Татар теле дәреслеге. Башлангыч мәктәп өчен, дүртенче кисәк / М.Х.Корбангалиев. - Казан: Татгосиздат., 1938. - 68 б.

4. Корбангалиев М.Х. Татар теле дәреслеге. Башлангыч мәктәп өчен, дүртенче кисәк / М.Х.Корбангалиев. - Казан: Тат-

госиздат., 1945. -30 б.

5. Корбангалиев М., Хисматуллин Х, Шакирова Р. Татар теле грамматикасы. Синтаксис. Казан: Тат. кит. нэшр., 1960. -158 б.

6. Хангилдин В., Шабанов Х. Грамматика һəм орфография дəреслеге. . – I басма / В.Хангилдин. – Казан, 1938.

7. Шакурова М.М. Становление и развитие методики преподавания татарского языка в иноязычной аудитории // Научный Татарстан. - 2010. - №3. - С. 207-214.